КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 март г.Казань № 240

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 5 август, 680 нче; 2021 ел, 31 август, 788 нче; 2021 ел, 7 сентябрь, 835 нче; 2021 ел, 25 ноябрь, 1127 нче; 2021 ел, 22 декабрь, 1266 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

дүртенче абзацта «, шул исәптән «Агросәнәгать комплексы продукциясен экспортлау» федераль проекты кысаларында» сүзләрен төшереп калдырырга;

унөченче абзацта «ачык грунт яшелчә культуралары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

ундүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Виноградчылыкны һәм шәраб әзерләүне үстерүне стимуллаштыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибен;

«Агросәнәгать комплексы продукциясен экспортлау» федераль проекты кысаларында чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибен;

Ана сарык һәм кәҗәләрнең, шул исәптән бер яшьтән өлкәнрәк ана сарык һәм кәҗә бәрәннәренең баш санын саклап калу һәм үстерү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибен;

Яшелчәләр җитештерүне үстерүне стимуллаштыруга юнәлдерелгән чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибен.»;

әлеге карар белән расланган Элиталы орлыкчылыкны үстерүгә юнәлдерелгән, федераль бюджеттан финанслаша торган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә;

1 пунктта:

«а» пунктчасында «хисап һәм» сүзләреннән соң «(яки)» сүзләрен өстәргә;

«б» пунктчасында «орлыкларын сатып алуга бәйле» сүзләрен «орлыкларын сатып алучыларга» сүзләренә алмаштырырга, «агымдагы» сүзеннән соң «һәм (яки) хисап» сүзләрен өстәргә, «чыгымнарының» сүзеннән соң «(әгәр бу чыгымнар элегрәк капланмаган булса)» сүзләрен өстәргә;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башлану көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 16 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Нигезләмәнең 6 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 7 пунктындагы икенче абзацы нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 8 һәм 9 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләренең бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган урнаштыру датасын.»;

7 пунктта:

уналтынчы абзацта «агымдагы» сүзеннән соң «һәм (яки) хисап» сүзләрен өстәргә;

унҗиденче абзацта «агымдагы» сүзеннән соң «һәм (яки) хисап» сүзләрен өстәргә;

8 пунктта:

икенче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктның «в» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

13 пунктта:

икенче абзацта «хисап һәм» сүзләреннән соң «(яки)» сүзен өстәргә, «элиталы орлыклары» сүзләрен «элиталы орлыкларын сатып алу» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «агымдагы финанс елы чыгымнары» сүзләрен «агымдагы һәм (яки) хисап финанс еллары чыгымнары» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктта:

дүртенче абзацта «хисап һәм» сүзләреннән соң «(яки)» сүзләрен өстәргә;

җиденче абзацта «хисап һәм» сүзләреннән соң «(яки)» сүзләрен, «элиталы орлыклары» сүзләрен «элиталы орлыкларын сатып алу» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктның дүртенче абзацында «агымдагы» сүзеннән соң «һәм (яки) хисап» сүзләрен өстәргә;

17 пунктта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга.

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Бирелгән субсидия Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә түбәндәге рәвештә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча шартлар бозылган, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап бирелмәгән очракларда;

субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгән очракта, Министрлык субсидия алучыга карата түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла торган штраф санкцияләрен ($V_{кайтару}$) куллана, почта аша тапшыру турындагы хәбәрнамәне теркәп, срогын һәм түләү реквизитларын күрсәтеп, килешүдә билгеләнгән, субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисап алынган датадан эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә штраф санкцияләрен куллану турында хәбәрнамә җибәрә:

$$V_{кайтару} = (V_{субсидия} \times k) \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{субсидия}$ – хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме;

k – субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган коэффициент:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән мәгънәсе;

S – килешүдә субсидия алучы өчен билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча мәгънәсе.

Штраф санкцияләрен исәпләп чыгарганда бары субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган коэффициентның уңай мәгънәләре кулланыла.»;

20 пунктта «Россия Федерациясе законнары нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга, «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Федераль бюджеттан финанслаша торган Күпьеллык үсентеләрне утыртуга, карауга һәм казып чыгаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башлану көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 17 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 7 пунктындагы икенче абзацы нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 8 һәм 9 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләренең бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган урнаштыру датасын.»;

8 пунктта:

икенче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктның «в» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Бу Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасы ($W_з$) нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_з = P_з \times 400\,000{,}0 \times K_з \times K_а \times K_с,$$

монда:

$P_з$ – үткән финанс елында һәм (яки) агымдагы финанс елында күпьеллык үсентеләрне (питомникларны кертеп) утырту мәйданы, гектар;

400 000,0 – күпьеллык үсентеләр (питомникларны кертеп) утыртылган 1 гектар мәйданга субсидия ставкасы, сум;

$K_з$ – 1 гектар утырту мәйданына ставканы исәпләп чыгарганда кулланыла торган коэффициент:

1 гектарга агачлар урнашу тыгызлыгы 799 данәгә кадәр булган бакчалар өчен – 1,0;

интенсив типтагы (сорт-ялганма комбинацияләрен саклап, орлыклы, төшле) бакчалар өчен: 1 гектарга агачлар урнашу тыгызлыгы 800 данәдән 1 249 данәгә кадәр булган бакчалар өчен – 1,0; 1 гектарга агачлар урнашу тыгызлыгы 1 250 данәдән 2 499 данәгә кадәр булган бакчалар өчен – 1,4; 1 гектарга агачлар урнашу тыгызлыгы 2 500 данәдән 3 499 данәгә кадәр булган бакчалар өчен – 1,7; 1 гектарга агачлар урнашу тыгызлыгы 3 500 данәдән булган бакчалар өчен – 3,0;

җимеш бирә торган агачлар питомниклары өчен – 3,0;

базис үсемлекләрнең ана үсентеләре өчен – 4,0;

җиләк бирә торган куак үсентеләре өчен – 1,1;

шпалер конструкцияләре урнаштырылган, җиләк бирә торган куак үсентеләре өчен – 1,4;

$К_а$ – түбәндәге ставкага карата кулланыла торган коэффициент:

хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан Министрлык һәм субсидия алучы арасында хисап финанс елында төзелгән килешүдә билгеләнгән, бу Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә бирелгән субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешелгән очракта, хисап финанс елы өчен факттагы нәтиҗә мәгънәсенең билгеләнгән мәгънәгә тигез, әмма 1,2 дән югары булмаган күләмдә кулланыла;

хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән, бу Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә бирелгән субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешелмәгән очракта, хисап финанс елы өчен факттагы нәтиҗә мәгънәсенең килешүдә билгеләнгән мәгънәгә тигез күләмдә кулланыла;

$К_с$ – субсидия алучы тарафыннан сорты һәм гибридлары Урта Идел төбәгендә файдаланырга рөхсәт ителгән, Селекция казанышларының дәүләт реестрына кертелгән күпьеллык үсентеләрнең утырту материалларын файдалану шартлары үтәлмәгән очракта, шулай ук мондый утырту материалының сорт сыйфатлары ГОСТ Р 53135-2008 туры килү шарты белән, ставкага карата 0,9 коэффициенты кулланыла.

Алучыга бирелә торган субсидия күләме, өстәлгән кыйммәткә салым түләү чыгымнарын тотып калып, үткән финанс елында һәм (яки) агымдагы финанс елында күпьеллык үсентеләрне утырту өчен субсидия алучы тарафыннан зыян күрелгән факттагы чыгымнар күләменең 70 процентыннан артып китә алмый.»;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Бу Тәртипнең 1 пунктындагы «а» пунктчасы ($W_{ух}$) нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{ух} = P_{ух} \times 20\,000{,}0 \times К \times К_б,$$

монда:

$P_{ух}$ – үткән финанс елында һәм (яки) агымдагы финанс елында күпьеллык үсентеләрне (питомникларны кертеп) карау мәйданы, гектар;

20 000,0 – күпьеллык үсентеләр (питомникларны кертеп) утыртылган 1 гектар мәйданга субсидия ставкасы, сум;

К – 1 гектар карау мәйданына ставканы исәпләп чыгарганда кулланыла торган коэффициент:

1 гектарга агачлар урнашу тыгызлыгы 799 данәгә кадәр булган бакчалар өчен – 1,0;

интенсив типтагы (сорт-ялганма комбинацияләрен саклап, орлыклы, төшле) бакчалар өчен: 1 гектарга агачлар урнашу тыгызлыгы 800 данәдән 1 249 данәгә кадәр булган бакчалар өчен – 1,0; 1 гектарга агачлар урнашу тыгызлыгы 1 250 данәдән 2 499 данәгә кадәр булган бакчалар өчен – 1,4; 1 гектарга агачлар урнашу тыгызлыгы 2 500 данәдән 3 499 данәгә кадәр булган бакчалар өчен – 1,7; 1 гектарга агачлар урнашу тыгызлыгы 3 500 данәдән булган бакчалар өчен – 3,0;

җимеш бирә торган агачлар питомниклары өчен – 3,0;

базис үсемлекләрнең ана үсентеләре өчен – 4,0;

җиләк бирә торган куак үсентеләре өчен – 1,1;

шпалер конструкцияләре урнаштырылган, җиләк бирә торган куак үсентеләре өчен – 1,4;

$К_б$ – түбәндәге ставкага карата кулланыла торган коэффициент:

хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан Министрлык һәм субсидия алучы арасында хисап финанс елында төзелгән килешүдә билгеләнгән, бу Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә бирелгән субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешелгән очракта, хисап финанс елы өчен факттагы нәтиҗә мәгънәсенең билгеләнгән мәгънәгә тигез, әмма 1,2 дән югары булмаган күләмдә кулланыла;

хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән, бу Тәртипнең 1 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә бирелгән субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешелмәгән очракта, хисап финанс елы өчен факттагы нәтиҗә мәгънәсенең килешүдә билгеләнгән мәгънәгә тигез күләмдә кулланыла.

Алучыга бирелә торган субсидия күләме, өстәлгән кыйммәткә салым түләү чыгымнарын тотып калып, үткән финанс елында һәм (яки) агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан күпьеллык үсентеләрне карап тору өчен зыян күрелгән факттагы чыгымнар күләменең 30 процентыннан артып китә алмый.»;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Бу Тәртипнең 1 пунктындагы «в» пунктчасы ($W_р$) нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_р = P_р \times 35\,000{,}0 \times К \times К_в,$$

монда:

$P_р$ – үткән финанс елында һәм (яки) агымдагы финанс елында файдаланудан алынган күпьеллык үсентеләрне төбе-тамыры белән алу мәйданы;

35 000,0 – файдаланудан алынган күпьеллык үсентеләрне төбе-тамыры белән (питомникларны кертеп) алу мәйданының 1 гектарына субсидия ставкасы, сум;

К – төбе-тамыры белән алу мәйданының 1 гектарына ставка исәпләп чыгарылганда кулланыла торган коэффициент:

1 гектарга агачлар урнашу тыгызлыгы 799 данәгә кадәр булган бакчалар өчен – 1,0;

интенсив типтагы (сорт-ялганма комбинацияләрен саклап, орлыклы, төшле) бакчалар өчен: 1 гектарга агачлар урнашу тыгызлыгы 800 данәдән 1 249 данәгә кадәр

булган бакчалар өчен – 1,0; 1 гектарга агачлар урнашу тыгызлыгы 1 250 данәдән 2 499 данәгә кадәр булган бакчалар өчен – 1,4; 1 гектарга агачлар урнашу тыгызлыгы 2 500 данәдән 3 499 данәгә кадәр булган бакчалар өчен – 1,7; 1 гектарга агачлар урнашу тыгызлыгы 3 500 данәдән булган бакчалар өчен – 3,0;

җимеш бирә торган агачлар питомниклары өчен – 3,0;

базис үсемлекләрнең ана үсентеләре өчен – 4,0;

җиләк бирә торган куак үсентеләре өчен – 1,1;

шпалер конструкцияләре урнаштырылган, җиләк бирә торган куак үсентеләре өчен – 1,4;

$К_в$ – түбәндәге ставкага карата кулланыла торган коэффициент:

хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан Министрлык һәм субсидия алучы арасында хисап финанс елында төзелгән килешүдә билгеләнгән, бу Тәртипнең 1 пунктындагы «в» пунктчасы нигезендә бирелгән субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешелгән очракта, хисап финанс елы өчен факттагы нәтиҗә мәгънәсенең билгеләнгән мәгънәгә тигез, әмма 1,2 дән югары булмаган күләмдә кулланыла;

хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән, бу Тәртипнең 1 пунктындагы «в» пунктчасы нигезендә бирелгән субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешелмәгән очракта, хисап финанс елы өчен факттагы нәтиҗә мәгънәсенең килешүдә билгеләнгән мәгънәгә тигез күләмдә кулланыла.

Алучыга бирелә торган субсидия күләме, өстәлгән кыйммәткә салым түләү чыгымнарын тотып калып, үткән финанс елында һәм (яки) агымдагы финанс елында күпьеллык үсентеләрне төбе-тамыры белән тартып алу өчен субсидия алучы тарафыннан зыян күрелгән факттагы чыгымнар күләменең 70 процентыннан артып китә алмый.»;

18 пунктта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга.

19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Бирелгән субсидия Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә түбәндәге рәвештә Татарстан Республикасы бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча шартлар бозылган, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап бирелмәгән очракларда;

субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгән очракта, Министрлык субсидия алучыга карата түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла торган штраф санкцияләрен ($V_{кайтару}$) куллана, почта аша тапшыру турындагы хәбәрнамәне теркәп, срогын һәм түләү реквизитларын күрсәтеп, килешүдә билгеләнгән, субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисап алынган датадан эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә штраф санкцияләрен куллану турында хәбәрнамә җибәрә:

$$V_{кайтару} = (V_{субсидия} \times k) \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{субсидия}$ – хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме;

k – субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган коэффициент:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән мәгънәсе;

S – килешүдә субсидия алучы өчен билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча мәгънәсе.

Штраф санкцияләрен исәпләп чыгарганда бары субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган коэффициентның уңай мәгънәләре кулланыла.»;

21 пунктта «Россия Федерациясе законнары нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга, «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Культуртехник, агроурманмелиоратив һәм гидромелиоратив чараларны үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан, шул исәптән «Агросәнәгать комплексы продукциясен экспортлау» федераль проекты кысаларында финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә;

исемендә «, шул исәптән «Агросәнәгать комплексы продукциясен экспортлау» федераль проекты кысаларында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта:

беренче абзацта «, шул исәптән «Агросәнәгать комплексы продукциясен экспортлау» федераль проекты (алга таба – Федераль проект) кысаларында» сүзләрен төшереп калдырырга;

унберенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башлану көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 16 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре

күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 7 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 8 пунктындагы икенче абзацы нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

әлеге Тәртипнең 9 һәм 10 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләренең бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган урнаштыру датасын.»;

6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«мелиорация проекты гамәлгә ашырылган җирләрдә өч елга авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүнең план буенча күләме булу.»;

8 пунктта:

икенче абзацка «Министрлык боерыгы белән расланган формада мелиорация проекты гамәлгә ашырылган җирләрдә өч елга авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүнең план буенча күләме турында белешмә кәгазе» сүзләрен өстәргә;

унөченче абзацка «, КС-14 номерлы статистик форма буенча кабул итү комиссиясе тарафыннан төзелеп беткән объектны кабул итү акты күчермәсе» сүзләрен өстәргә;

егерме җиденче абзацка «, КС-14 номерлы статистик форма буенча кабул итү комиссиясе тарафыннан төзелеп беткән объектны кабул итү акты күчермәсе» сүзләрен өстәргә;

утыз беренче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

9 пунктта:

икенче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның «в» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

14 пунктта:

икенче абзацта «чыгымнары» сүзе алдына «, проект-смета документациясен әзерләү» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «чыгымнары» сүзе алдына «, проект-смета документациясен әзерләү» сүзләрен өстәргә;

15 пунктта:

өченче абзацта «$W_к = P_к \times 70\%$,» сүзләрен «$W_к = P_к \times 50\%$,» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «$W_а = P_а \times 90\%$,» сүзләрен «$W_а = P_а \times 50\%$,» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацта «$W_г = P_г \times 70\%$,» сүзләрен «$W_г = P_г \times 50\%$,» сүзләренә алмаштырырга;

ундүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Бу Тәртипнең 1 пунктындагы «а» һәм «в» пунктчаларында каралган чаралар буенча субсидия исәпләп чыгарылганда кулланыла торган төзелеш, монтаж эшләре һәм башка төр эшләр башкару кыйммәте Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган 1 гектар җир мәйданына эшләр кыйммәтенең иң чик күләмен исәпкә алып исәпләп чыгарылган эшләр кыйммәтенең иң чик күләменнән артып китә алмый.

Әгәр тиешле җирләрнең 1 гектар мәйданына эшләр кыйммәте алар буенча билгеләнгән иң чик кыйммәттән кимрәк булса, исәпләп чыгарылганда авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләр тарафыннан белдерелгән 1 гектар мәйданда үткәрелә торган эшләр кыйммәте кулланыла.»;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Субсидия бирүнең нәтиҗәләре:

1 пунктның «а» пунктчасы нигезендә – субсидия бирелгән елның 31 декабре хәленә карата культуртехник чаралар үткәрү исәбенә әйләнешкә җәлеп ителгән авыл хуҗалыгы җирләре мәйданы, гектар;

1 пунктның «б» пунктчасы нигезендә – субсидия бирелгән елның 31 декабре хәленә карата авыл хуҗалыгы җирләрен җил эрозиясеннән һәм корудан саклау һәм саклап калу максатларында агроурманмелиорация чараларын үткәрү мәйданы (утырту мәйданы), гектар;

1 пунктның «в» пунктчасы нигезендә – субсидия бирелгән елның 31 декабре хәленә карата гомуми һәм индивидуаль файдаланудагы мелиорация системаларын реконструкцияләү, техник яңадан җиһазландыру һәм яңаларын төзү исәбенә файдалануга тапшырылган, мелиорацияләнә торган җирләр мәйданы, гектар.»;

17 пунктта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга.

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Бирелгән субсидия Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә түбәндәге рәвештә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән

Министрлык һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча шартлар бозылган, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап бирелмәгән очракларда;

субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгән очракта, Министрлык субсидия алучыга карата түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла торган штраф санкцияләрен ($V_{кайтару}$) куллана, почта аша тапшыру турындагы хәбәрнамәне теркәп, срогын һәм түләү реквизитларын күрсәтеп, килешүдә билгеләнгән, субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисап алынган датадан эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә штраф санкцияләрен куллану турында хәбәрнамә җибәрә:

$$V_{кайтару} = (V_{субсидия} \times k) \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{субсидия}$ – хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме;

k – субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган коэффициент:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән мәгънәсе;

S – килешүдә субсидия алучы өчен билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча мәгънәсе.

Штраф санкцияләрен исәпләп чыгарганда бары субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган коэффициентның уңай мәгънәләре кулланыла.»;

20 пунктта «Россия Федерациясе законнары нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга, «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Чәчүлекләрдә әче туфракны известьлау өлкәсендә чаралар үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидияләр бирү тәртибендә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башлану көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның һәм тиешле муниципаль районда авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренең (алга таба - Идарәнең) исемнәрен, урнашу урыннарын, почта адресын, электрон почтасы адресын;

бу Тәртипнең 18 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 7 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 8 пунктындагы икенче абзацы нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 9 – 11 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләренең бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган урнаштыру датасын.»;

6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«мелиорация проекты гамәлгә ашырылган җирләрдә өч елга авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүнең план буенча күләме булу.»;

8 пунктта:

икенче абзацка «Министрлык боерыгы белән расланган формада мелиорация проекты гамәлгә ашырылган җирләрдә өч елга авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүнең план буенча күләме турында белешмә кәгазе» сүзләрен өстәргә;

9 пунктта:

икенче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктның икенче абзацында «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктның «в» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Бу Тәртипнең 1 пункты нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (W) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = R_{с.з.} \times 50\%,$$

монда:

$R_{с.з.}$ – агымдагы финанс елында һәм (яки) хисап финанс елында субсидия алучының өстәлгән кыйммәткә салым түләү чыгымнарын исәпкә алмыйча әче туфракларны известлауга факттагы чыгымнары, сум.»;

19 пунктта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга.

20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Бирелгән субсидия Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә түбәндәге рәвештә Татарстан Республикасы бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча шартлар бозылган, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап бирелмәгән очракларда;

субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгән очракта, Министрлык субсидия алучыга карата түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла торган штраф санкцияләрен ($V_{кайтару}$) куллана, почта аша тапшыру турындагы хәбәрнамәне теркәп, срогын һәм түләү реквизитларын күрсәтеп, килешүдә билгеләнгән, субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисап алынган датадан эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә штраф санкцияләрен куллану турында хәбәрнамә җибәрә:

$$V_{кайтару} = (V_{субсидия} \times k) \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{субсидия}$ – хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме;

k – субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган коэффициент:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән мәгънәсе;

S – килешүдә субсидия алучы өчен билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча мәгънәсе.

Штраф санкцияләрен исәпләп чыгарганда бары субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган коэффициентның уңай мәгънәләре кулланыла.»;

22 пунктта «Россия Федерациясе законнары нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга, «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Майлы культуралар җитештерүне арттыру чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

1 пунктның икенче абзацында «һәм (яки) көнбагыш орлыклары» сүзләрен төшереп калдырырга, «сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән» сүзләрен төшереп калдырырга, «май культуралары» сүзләреннән соң «җитештерү күләме артуның» сүзләрен өстәргә, «агымдагы финанс елында» сүзләре алдына «тиешле финанс елы алдындагы бер елдан биш елга кадәрге чорга майлы культураларның тулаем җыемы буенча уртача күрсәткечкә карата» сүзләрен өстәргә;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башлану көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы, Министрлыкның һәм аның тиешле муниципаль райондагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренең (алга таба – Идарәләр) исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

бу Тәртипнең 18 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 7 пунктындагы икенче абзацы нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 8 – 10 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләренең бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган урнаштыру датасын.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы Идарәгә түбәндәгеләрне тапшыра:

сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат, сайлап алуда катнашучының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлауда катнашучы турындагы, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка турындагы мәгълүматны һәм сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алу белән бәйле булган башка мәгълүматны бастырып чыгару, шулай ук шәхси мәгълүматларны (физик затлар өчен) эшкәртү өчен ризалыгы бирелгән, түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча тутырылган заявка;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси  эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан билгеләнгән тәртиптә таныкланган өземтә йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси  эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан  Федераль салым хезмәтенең рәсми сайтыннан  гариза бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән белешмәләр ( сайлап алуда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта  Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

салым органының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын раслый торган, заявка бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән белешмә кәгазе (сайлап алуда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

Министрлык тарафыннан расланган формада майлы культураларның районлаштырылган сортлары һәм гибридлары чәчелгән һәм (яки) чәчәргә планлаштырыла торган чәчү мәйданнары турында «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы тарафыннан таныкланган һәм майлы культуралар чәчелгән һәм (яки) чәчәргә планлаштырыла торган мәйданнарның 1 гектарына актив матдәне исәпләп чыгарганда майлы культуралар җитештергәндә кулланыла торган ашламаларны кертү турында «Татарский» агрохимия хезмәте үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесе яки «Альметьевская» агрохимия хезмәте станциясе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан таныкланган мәгълүмат;

Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча бирелергә тиешле субсидия турында исәп-хисап белешмә кәгазен;

«Уңыш өчен чәчү йомгаклары турында белешмәләр» дигән 4-СХ яки «Уңыш

өчен чәчү йомгаклары турында белешмәләр» дигән 1-фермер формасы буенча агымдагы елның уңышы өчен чәчелгән һәм (яки) чәчергә планлаштырыла торган майлы культуралар мәйданнары турында мәгълүмат;

Министрлык боерыгы белән расланган формада агымдагы финанс елында майлы культуралар җитештерү чыгымнары турындагы белешмә кәгазе, аңа фактта тотылган чыгымнарны раслый торган документлар (сатып алу-сату (кайтарту), универсаль тапшыру документлары, товар накладнойлары, түләү документлары күчермәләре) теркәлә;

Министрлык боерыгы белән расланган формада «Авыл хуҗалыгы культуралары уңышын җыю турында белешмәләр» дигән 29-СХ яки «Авыл хуҗалыгы культуралары уңышын җыю турында белешмәләр» дигән 2-фермер статистик хисаплар мәгълүматлары нигезендә төзелгән агымдагы финанс елына кадәрге бер елдан алып биш елга кадәрге чорда майлы культураларның тулаем җыемы буенча белешмә кәгазе.

Тапшырылган документларның күчермәләре сайлап алуда катнашучы тарафыннан таныклана.

Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Сайлап алуда катнашучы, кирәк булганда, заявкалар бирү өчен билгеләнгән срок эчендә заявканы кабат бирергә хокуклы, шул ук вакытта заявка кергән көнендә чират тәртибендә теркәүгә алына.»;

8 пунктта:

икенче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктның икенче абзацында «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның «в» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешләре – майлы культуралар җитештерүгә бәйле чыгымнар (ашламалар, орлыклар, үсемлекләрне саклау чаралары, ягулык-майлау материаллары сатып алу өчен түләү).»;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Бу Тәртипнең 1 пункты нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (W) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = Q \times C \times K_{согл} \times K_{сем} \times K_{уд},$$

монда:

Q – тиешле финанс елы алдындагы бер елдан биш елга кадәрге чорга майлы культураларның тулаем җыемы буенча уртача күрсәткечкә карата агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан түбәндәге формула буенча билгеләнә торган үз җитештерендәге майлы культуралар җитештерү күләменең артуы, тонна:

$$Q = B_{сред} \times 0{,}1,$$

монда $B_{сред}$ – тиешле финанс елына кадәрге бер елдан алып биш елга кадәрге чорда майлы культураларның тулаем җыемы буенча уртача күрсәткече, тонна;

C – Министрлык боерыгы белән раслана, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган бер тонна җитештерү күләме артуга субсидия ставкасы:

$$C = \frac{V}{P},$$

монда:

V – бюджет ассигнованиеләре һәм бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка бюджет акчасын алучы буларак билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары күләме, сум;

P – тиешле финанс елы алдындагы бер елдан биш елга кадәрге чорга майлы культураларның тулаем җыемы буенча уртача күрсәткечкә карата агымдагы финанс елында Татарстан Республикасы буенча Министрлык тарафыннан билгеләнә торган майлы культуралар җитештерү күләменең планлаштырыла торган артуы, тонна;

$K_{согл}$ – түбәндәге ставкага карата кулланыла торган коэффициент:

хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан Министрлык һәм субсидия алучы арасында хисап финанс елында төзелгән килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешелгән очракта, хисап финанс елы өчен факттагы нәтиҗә мәгънәсенең билгеләнгән мәгънәгә тигез, әмма 1,2 дән югары булмаган күләмдә кулланыла;

хисап финанс елында субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешелмәгән очракта, хисап финанс елы өчен факттагы нәтиҗә мәгънәсенең килешүдә билгеләнгән мәгънәгә тигез күләмдә кулланыла;

$K_{сем}$ – субсидия алучы тарафыннан бу Тәртипнең 1 пунктындагы дүртенче абзацында каралган шартлар үтәлмәгән очракта, 0,25 коэффициенты, 2023 елның 1 гыйнварыннан башлап, 0 коэффициенты кулланыла;

$K_{уд}$ – субсидия алучы тарафыннан бу Тәртипнең 1 пунктындагы бишенче абзацында каралган шарт үтәлмәгән очракта, 0,25 коэффициенты, 2023 елның 1 гыйнварыннан башлап, 0 коэффициенты кулланыла.»;

17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Субсидия бирү нәтиҗәсе – агымдагы финанс елының 31 декабренә тиешле финанс елы алдындагы бер елдан биш елга кадәрге чорга майлы культураларның тулаем җыемы буенча уртача күрсәткечкә карата агымдагы финанс елында майлы культуралар җитештерү күләменең артуы (тоннада).»;

18 пунктта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга.

19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Бирелгән субсидия Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә түбәндәге рәвештә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча шартлар бозылган, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап бирелмәгән очракларда;

субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгән очракта, Министрлык субсидия алучыга карата түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла торган штраф санкцияләрен ($V_{кайтару}$) куллана, почта аша тапшыру турындагы хәбәрнамәне теркәп, срогын һәм түләү реквизитларын күрсәтеп, килешүдә билгеләнгән, субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисап алынган датадан эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә штраф санкцияләрен куллану турында хәбәрнамә җибәрә:

$$V_{кайтару} = (V_{субсидия} \times k) \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{субсидия}$ – хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме;

k – субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган коэффициент:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән мәгънәсе;

S – килешүдә субсидия алучы өчен билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча мәгънәсе.

Штраф санкцияләрен исәпләп чыгарганда бары субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган коэффициентның уңай мәгънәләре кулланыла.»;

21 пунктта «Россия Федерациясе законнары нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга, «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

Товар ана сарык һәм кәҗәләрнең баш санын карап тоту чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башлану көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның һәм тиешле муниципаль районда авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренең (алга таба - Идарәнең) исемнәрен, урнашу урыннарын, почта адресын, электрон почтасы адресын;

бу Тәртипнең 17 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 7 пунктындагы икенче абзацы нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 8 – 10 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләренең бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган урнаштыру датасын.»;

8 пунктта:

икенче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктның икенче абзацында «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның «в» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

«сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән сайлап алуны үткәрү срогы тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә тапшырылган документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә, Министрлык боерыгы белән расланган формаларда бирелергә тиешле субсидияләр турында җыелма исәп-хисап белешмә кәгазен, Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре турында реестр формалаштыра һәм аларны Татарстан Республикасының бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы аша Министрлыкка җибәрә.»;

9 пунктның икенче абзацында «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Субсидия күләмнәре;

а) сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән югары, беренче һәм икенче сортлы сыер сөте өчен субсидия алучыга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән һәм федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына

финанслашу акчасы исәбеннән бирелә торган ($W_{нi}$) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_{нi} = V_{нi} \times S_{н} \times (К + К_{диф}),$$

монда:

$V_{нi}$ – агымдагы финанс елының гыйнвары – февралендә алучы тарафыннан сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен төяп җибәрелгән югары, беренче һәм икенче сортлы сыер сөте күләме;

$S_{н}$ – сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен төяп җибәрелгән югары, беренче һәм икенче сортлы 1 килограмм сыер сөтенә Министрлык боерыгы белән раслана һәм түбәндәге формула буенча билгеләнә торган ставка:

$$S_{н} = \frac{R_{m}}{\sum \left( V_{нi} \times \left( К + К_{диф} \right) \right)},$$

монда:

$R_{m}$ – сөт бирә торган терлекчелектә продуктивлыкны арттыру чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетында сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртү өчен төяп җибәрелгән югары, беренче һәм икенче сортлы 1 килограмм сыер сөтенә каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына финанслашу акчасы күләме;

К - ставкага карата арттыру коэффициенты:

1,3 – хисап елында сыерларның уртача сөт продуктивлыгы республика буенча уртача продуктивлыктан югарырак, әмма 5 000 килограммнан ким булмаган субсидия алучылар өчен;

1,3 – «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Федераль законда билгеләнгән кече предприятие критерийларына туры килә торган субсидия алучыларга сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән сөт күләме өчен;

$К_{диф}$ – субсидия алучыларга һәр гамәлгә ашырылган чара өчен ставкага 1,05 күләмендә арттыру коэффициенты:

силос-сенаж траншеяләрен һәм курганнарын 100 процент паспортлаштыру;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 26 август, б-1647 нче боерыгы нигезендә төзелгән хайваннарны теркәү һәм исәпкә алу буенча ведомствоара эшче төркем беркетмәсендә билгеләнгән гомуми баш санынннан кимендә 95 процентын тиешле мәгълүмати автоматлаштырылган системасында теркәү һәм исәпкә алу һәм яңа туган яшь терлекнең көн саен теркәү;

штат расписаниесе нигезендә зооветеринария белгечләре белән комплектлану яки ветеринария хезмәте күрсәтүгә шартнамә булу;

көтү белән идарә итүнең автоматлаштырылган программасы гамәлгә кертелгән;

терлекләрне ашату белән идарә итүнең автоматлаштырылган программасы кертелгән;

мөгезле эре терлекнең баш санын саклап калу – субсидия бирелгән елга кадәрге елда үлемнең үрчемгә иң күбе биш проценты;

заявка бирелгән айның беренче числосына мөгезле эре терлек лейкозы очраклары булмау;

сыерларны һәм таналарны ясалма орлыкландыру белән 100 процент колачлау;

а) сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән кәҗә сөте өчен субсидия алучыга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән һәм федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына финанслашу акчасы исәбеннән бирелә торган (W) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = V \times S,$$

монда:

V – агымдагы финанс елының гыйнвары – февралендә субсидия алучы тарафыннан сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән кәҗә сөте күләме;

S – сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән 1 килограмм кәҗә сөтенә Министрлык боерыгы белән раслана һәм түбәндәге формула буенча билгеләнә ставка:

$$S = S_н \times K_k,$$

монда:

$K_k$ – сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән уртача 1 литр кәҗә сөте бәясенең уртача 1 литр кәҗә сөте бәясенә нисбәтеннән чыгып, Министрлык боерыгы белән раслана торган коэффициент.

Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме агымдагы финанс елының гыйнвары – февралендә сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән сыер һәм кәҗә сөтен җитештерү өчен субсидия алучы тарафыннан зыян күрелгән факттагы чыгымнардан артып китә алмый.»;

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Сөтле терлекчелектә продуктивлыкны арттыруга юнәлдерелгән, субсидия алучыга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бирелә торган субсидия күләме ($W_г$) (сумнарда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_г = W_я + W_ф,$$

монда:

$W_я$ – агымдагы елның гыйнвары өчен сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән югары һәм беренче сортлы сыер сөте өчен субсидия алучыга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W_я = V_я \times S_я \times (K_м + K_{диф}),$$

монда:

$V_я$ – агымдагы елның гыйнварында субсидия алучы тарафыннан сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән югары һәм беренче сортлы сыер сөтенең күләме;

$S_я$ – агымдагы елның гыйнварында сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән югары һәм беренче сортлы сыер сөтенең 1 килограммы өчен Министрлык боерыгы белән раслана, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган субсидия ставкасы:

$$S_я = \frac{\frac{W}{2}}{\sum \left(V_я \times (K_м + K_{диф})\right)},$$

монда:

W – тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга каралган ассигнованиеләр күләме;

$K_м$ – ставкага арттыру коэффициент:

1,3 – хисап елында сыерларның уртача сөт продуктивлыгы республика буенча уртача продуктивлыктан югарырак, әмма 5 000 килограммнан ким булмаган субсидия алучылар өчен;

1,3 – «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Федераль законда билгеләнгән кече предприятие критерийларына туры килә торган субсидия алучыларга сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән сөт күләме өчен;

$W_ф$ – агымдагы елның февралендә сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән югары һәм беренче сортлы сыер сөте өчен субсидия алучыга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән бирелә һәм түбәндәге формула буенча билгеләнә торган субсидия күләме:

$$W_ф = V_ф \times S_ф \times (K_м + K_{диф}),$$

монда:

$V_ф$ – агымдагы елның февралендә субсидия алучы тарафыннан сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән югары һәм беренче сортлы сыер сөтенең күләме;

$S_ф$ – агымдагы елның февралендә сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән югары һәм беренче сортлы сыер сөтенең 1 килограммы өчен субсидиянең Министрлык боерыгы белән раслана һәм түбәндәге формула буенча билгеләнә торган ставкасы:

$$S_ф = \frac{\frac{W}{2}}{\sum \left(V_ф \times (K_м + K_{диф})\right)}.$$

Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме агымдагы финанс елының гыйнвары – февралендә сатылган һәм (яки) үзендә эшкәртүгә төяп җибәрелгән сыер сөтен җитештерү өчен субсидия алучы тарафыннан зыян күрелгән факттагы чыгымнардан артып китә алмый.»;

20 пунктта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга.

21 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21. Бирелгән субсидия Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә түбәндәге рәвештә Татарстан Республикасы бюджеты керемен кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча шартлар бозылган, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап бирелмәгән очракларда;

субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгән очракта, Министрлык субсидия алучыга карата түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла торган штраф санкцияләрен ($V_{кайтару}$) куллана, почта аша тапшыру турындагы хәбәрнамәне теркәп, срогын һәм түләү реквизитларын күрсәтеп, килешүдә билгеләнгән, субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисап алынган датадан эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә штраф санкцияләрен куллану турында хәбәрнамә җибәрә:

$$V_{кайтару} = (V_{субсидия} \times k) \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{субсидия}$ – хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме;

k – субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган коэффициент:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән мәгънәсе;

S – килешүдә субсидия алучы өчен билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча мәгънәсе.

Штраф санкцияләрен исәпләп чыгарганда бары субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган коэффициентның уңай мәгънәләре кулланыла.»;

23 пунктта «Россия Федерациясе законнары нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга, «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Сыерларның баш санын арттыру юлы белән сөт җитештерүне арттыруны стимуллаштыру өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башлану көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның һәм тиешле муниципаль районда авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренең (алга таба - Идарәнең) исемнәрен, урнашу урыннарын, почта адресын, электрон почтасы адресын;

бу Тәртипнең 17 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 7 пунктындагы икенче абзацы нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 8 – 10 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләренең бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган урнаштыру датасын.»;

6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Сайлап алуда катнашучы заявка бирү датасына түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы http://subsidiya.tatar.ru яки http://subsidiya.tatarstan.ru адресы буенча «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасының рәсми сайтында (алга таба – сервис) йә «Минем субсидияләр» мобиль кушымтасында, Бердәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталының (www.gosuslugi.ru) «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмат-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» мәгълүмат системасында расланган теркәлү язуыннан файдаланып, шәхси кабинет булдыра, аның түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, шул исәптән сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат, сайлап алуда катнашучының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлауда катнашучы турындагы, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка турындагы мәгълүматны һәм сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алу белән бәйле булган башка мәгълүматны бастырып чыгару, шулай ук шәхси мәгълүматларны (физик затлар өчен) эшкәртү өчен ризалыгы бирелгән, Министрлык боерыгы белән расланган формада языла торган заявка тутыра һәм түбәндәге документларның сканер ярдәмендә алынган күчермәләрен сервиска кертәләр:

хисап финанс елына кадәрге биш елга сөт җитештерүнең уртача күләменә (тонна) карата хисап елына сөт күләме җитештерүнең артуы турында мәгълүмат;

хисап финанс елы ахырына һәм хисап финанс елына кадәрге ел ахырына сөт бирә торган сыерларның баш саны турында статистик хисаплар формалаштырылган мәгълүмат;

субсидия бирү өчен мөрәҗәгать иткән айның 1 нче көненә сөт бирә торган сыерларның баш саны турында статистик хисаплар төзелгән мәгълүмат;

хисап финанс елына сөт бирә торган сыерларның сөт бирү продуктивлыгының уртача республика күрсәткечәнә карата хисап финанс елына сөт бирә торган сыерларның сөт продуктивлылыгы турында статистика хисаплары формалаштырылган мәгълүмат;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча бирелергә тиешле субсидия турында исәп-хисап белешмә кәгазе;

бер баш чыгымнарын күрсәтеп, статистик хисаплар формалаштырылган хисап финанс елына сөт бирә торган сыерларны карап тоту чыгымнары турында мәгълүмат;

салым салуның кулланыла торган системасы турында салым органыннан белешмә (салым түләүченең өстәлгән кыйммәткә салым исәпләүгә һәм түләүгә бәйле бурычларын үтәүдән азат итү хокукыннан файдаланучы сайлап алуда катнашучылар өчен чыгымнарның бер өлеше бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен чыгымнар суммасыннан чыгып (өстәлгән кыйммәткә салым суммасын кертеп) гамәлгә ашырыла);

СП-51 формасы буенча хисап чорына терлек һәм кош-корт хәрәкәте турында хисап;

банктан өземтә һәм агымдагы финанс елына кадәрге елда мөгезле эре терлек сатып алуны раслый торган түләү йөкләмәләре (түләүче банк тарафыннан

танылыкланган аванс түләүләрен кертеп);

агымдагы финанс елына кадәрге елда мөгезле эре терлек кайтару шартнамәсе;

агымдагы финанс елына кадәрге елда мөгезле эре терлек сатып алуга йөкнамә яки көтү ведомосте, счет-фактуралар һәм ветеринария таныклыклары.

Сервис белән автоматлаштырылган режимда алына торган документлар:

Юридик затларның бердәм дәүләт ресстрыннан яки Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 5 пунктындагы икенче абзацында билгеләнгән критериена һәм 6 пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацларында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган өземтә;

сайлап алуда катнашучының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын раслый торган салым органының белешмә кәгазе.

Сайлап алуда катнашучы заявкаларны кабул итү срогы чыкканга кадәр заявканы теләсә кайсы вакытта кире алырга, җитешсезлекләрен бетерергә һәм заявкалар кабул итү өчен билгеләнгән срок эчендә төзәтелгән документларның тулы пакетын кабат бирергә хокуклы. Шул ук вакытта документлар пакеты белән төзәтелгән заявка кабат кергән көнендә заявкалар керү чираты тәртибе буенча теркәлә.»;

8 пунктта:

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

өченче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктның икенче абзацында «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның «в» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

18 пунктта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга.

19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Бирелгән субсидия Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә түбәндәге рәвештә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча шартлар бозылган, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап бирелмәгән очракларда;

субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгән очракта, Министрлык субсидия алучыга карата түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла торган штраф санкцияләрен ($V_{кайтару}$) куллана, почта аша тапшыру турындагы хәбәрнамәне теркәп, срогын һәм түләү реквизитларын күрсәтеп, килешүдә билгеләнгән, субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисап алынган датадан эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә штраф санкцияләрен куллану турында хәбәрнамә җибәрә:

$$V_{кайтару} = (V_{субсидия} \times k) \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{субсидия}$ – хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме;

k – субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган коэффициент:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән мәгънәсе;

S – килешүдә субсидия алучы өчен билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча мәгънәсе.

Штраф санкцияләрен исәпләп чыгарганда бары субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган коэффициентның уңай мәгънәләре кулланыла.»;

21 пунктта «Россия Федерациясе законнары нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга, «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Нәселле терлекчелеккә ярдәм күрсәтү өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

1 пунктның дүртенче абзацында «агымдагы финанс елы» сүзләрен «хисап һәм (яки) агымдагы финанс еллары» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башлану көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 15 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла

торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 7 пунктындагы икенче абзацы нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 8 һәм 9 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләренең бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган урнаштыру датасын.»;

7 пунктта:

уникенче абзацта «агымдагы финанс елында» сүзләрен «хисап һәм (яки) агымдагы финанс елларында» сүзләренә алмаштырырга;

унөченче абзацта «агымдагы финанс елында» сүзләрен «хисап һәм (яки) агымдагы финанс елларында» сүзләренә алмаштырырга;

ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«йөкнамә яки күчү ведомосте, хисап һәм (яки) агымдагы финанс елларында сөт һәм ир бирә торган мөгезле эре терлекнең нәселле яшь терлеген кайтартуга счет-фактура, сатып алынган, сөт һәм ит бирә торган нәселле яшь терлек өчен «Меркурий» дәүләт мәгълүмат системасыннан алынган ветеринария ияртчен документлар (ветеринария таныклыгы, ветеринаррия белешмә кәгазе) күчермәсе;»;

унбишенче абзацта татар текстында «реестры бирелә» сүзләреннән соң «, аңа нәселле терлек таныклыкларының яки паспортларының беренче 10 данәсе күчермәләре теркәлә» сүзләрен өстәргә;

уналтынчы абзацта «агымдагы финанс елында» сүзләрен «хисап һәм (яки) агымдагы финанс елларында» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта:

икенче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «биш көн» сүзләрен «ун көн» сүзләренә алмаштырырга, «сайлап алуда үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктның «в» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

14.3 пунктның дүртенче абзацында «агымдагы финанс елында» сүзләрен «хисап һәм (яки) агымдагы финанс елларында» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктта:

дүртенче абзацта «агымдагы финанс елында» сүзләрен «хисап һәм (яки) агымдагы финанс елларында» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хисап финанс елының 31 декабренә сөт һәм ит бирә торган мөгезле эре ана терлекнең баш саны булмаган яки хисап һәм (яки) агымдагы финанс елында сөт һәм ит бирә торган мөгезле эре терлекнең сатып алынган яшь терлегенең баш саны әлеге датага булган нәселле ана баш санынннан артып киткән субсидия алучылар өчен – 31 декабрьгә ел саен, субсидия бирелгән елдан башлап, өч ел эчендә сөт һәм ит бирә торган мөгезле эре терлекнең гомуми баш санын хисап һәм (яки) агымдагы финанс елларында сатып алынган баш саныннан ким булмаган, әмма сатып алынган ай башына булган баш саныннан ким булмаган дәрәҗәдә саклап калу.»;

16 пунктта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга.

17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Бирелгән субсидия Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә түбәндәге рәвештә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча шартлар бозылган, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап бирелмәгән очракларда;

субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгән очракта, Министрлык субсидия алучыга карата түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла торган штраф санкцияләрен ($V_{кайтару}$) куллана, почта аша тапшыру турындагы хәбәрнамәне теркәп, срогын һәм түләү реквизитларын күрсәтеп, килешүдә билгеләнгән, субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисап алынган датадан эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә штраф санкцияләрен куллану турында хәбәрнамә җибәрә:

$$V_{кайтару} = (V_{субсидия} \times k) \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{субсидия}$ – хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме;

k – субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган коэффициент:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән мәгънәсе;

S – килешүдә субсидия алучы өчен билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча мәгънәсе.

Штраф санкцияләрен исәпләп чыгарганда бары субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган коэффициентның уңай мәгънәләре кулланыла.»;

19 пунктта «Россия Федерациясе законнары нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга, «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

әлеге Тәртипкә кушымтада:

2 пунктта «15» саннарын «30» саннарына алмаштырырга.

4 пунктта «10» саннарын «20» саннарына алмаштырырга, «биш» сүзен «ун» сүзенә алмаштырырга, «Актта» сүзләреннән соң «хисап финанс елының раслый торган документлары нигезендә» сүзләрен өстәргә;

5 пунктта:

икенче абзацта «– 350» саннарын «һәм аннан күбрәк» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Хуҗалык тарафыннан хуҗалык категориясен билгеләү турында гариза тапшырылмаганда әлеге хуҗалыкка III категория бирелә.»;

«Нәселле терлек хуҗалыкларының селекция-нәсел эше торышын бәяләү күрсәткечләре» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Селекция-нәсел эше торышын бәяләү күрсәткечләре
нәселле терлек хуҗалыклары

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Мәгълүматлар чыганагы | Бәя баллда |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Нәселле терлек хуҗалыкның җитештерү күрсәткечләре | | |
| 1.1. | 305 көнгә уртача, аннан да күбрәк сугым, кг | Хуҗалык мөһере белән таныкланган 7-мол формасы (бонитировка ведомосте) | |
| | 8 000 | | 5 |
| | 9 000 | | 10 |
| | 10 000 һәм аннан да күбрәк | | 15 |
| 1.2. | 100 сыердан бозаулар туу (баш), кимендә, % | Хуҗалык мөһере белән таныкланган 24-СХ формасы | |
| | 85 | | 5 |
| | 87 | | 10 |
| | 90 | | 15 |
| 1.3. | Сату күрсәткече 10нан артып киткән 100 сыер (баш) яшь терлек сату (1 проценттан артып киткән өчен 2 балл бирелә) | Хуҗалык мөһере белән таныкланган хуҗалык хисабы | . |
| 1.4. | Унификацияләнгән номерлар бирелгән баш санын идентификацияләү, % (һәр 1% өчен 0,4 балл бирелә) | Тикшерү вакытында хайваннарны теркәү системасыннан чыгару | 40 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 1.5. | Дәүләт ярдәме белән хуҗалыкның авыл хуҗалыгы хайваннарын иминләштерү | Тикшерү вакытына дәүләт ярдәме белән авыл хуҗалыгы хайваннарын иминләштерүнең гамәлдәге шартнамәсе күчермәсе, түләү йөкләмәсе | 30 |
| 2. | Икътисадый күрсәткечләр | | |
| 2.1. | Хисап елы өчен предприятиедә хезмәт җитештерүчәнлеге (баллар бу күрсәткечнең мәгънәсе тармак буенча уртача республика күрсәткеченнән арткан очракта бирелә) | Хисап чоры өчен бухгалтерлык хисаплылыгы | 5 |
| 2.2. | Предприятиедә уртача айлык хезмәт хакы (баллар бу күрсәткеч тармак буенча уртача республика күрсәткеченнән арткан очракта бирелә) | | 5 |
| 3. | Югары квалификацияле кадрлар белән тәэмин ителеш | | |
| 3.1. | Зоотехник-селекционер булу | Хуҗалык мөһере белән таныкланган хезмәт шартнамәсе күчермәсе | 3 |
| 3.2. | Нәселле терлекне исәпкә алучы булу | | 3 |
| 3.3. | Ветеринария белгече булу | | 3 |
| 3.4. | Хисап елына зоотехник-селекционер, нәселле терлекне исәпкә алучы, ветеринария белгече тарафыннан терлекчелек мәсьәләләре буенча квалификация күтәрү курсын үтүне раслый торган документлар булу (һәр белгеч өчен 3 балл бирелә, әмма соңгы балл 9 баллдан артмый) | Хуҗалык мөһере белән таныкланган квалификация күтәрүне үтүне раслый торган документ күчермәсе | 9 |
| 3.5. | Зооветеринария белгечлеге буенча белем алучы студент-стипендиат булу (балл һәр белгечкә бирелә) | Хуҗалык мөһере белән таныкланган шартнамә күчермәсе | 3 |
| 3.6. | Белгечнең (зоотехник-селекционер, нәселле терлекне исәпкә алучының) терлекчелек тармагындагы конкурсларда призлы урыны булу | Конкурс беркетмәсе күчермәсе | 3 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 4. | Нәселле терлек эшен исәпкә алу өчен җиһаз | | |
| 4.1. | Электрон исәпкә алу системасы белән интеграцияләнгән үлчәүләр булу | | 7 |
| 4.2. | Өлкән хайваннарны үлчәү өчен үлчәүләр булу | | . |
| 4.3. | Бонитировка үткәрүне тәэмин итү өчен экстерьер билгеләрен бәяләү өчен үлчәү таягы булу | | . |
| 4.4. | Бонитировка үткәрүне тәэмин итү өчен экстерьер билгеләрен бәяләү өчен циркуль булу | | . |
| 4.5. | Бонитировка үткәрүне тәэмин итү өчен экстерьер билгеләрен бәяләү өчен үлчәү лентасы булу | | . |
| 5. | Зоотехника документациясен алып бару | | |
| 5.1. | Тикшерү вакытында Дюар савытында саклана торган нәсел үрчетүче үгезләр орлыгына нәсел терлеге таныклыклары булу | Хуҗалык мөһере белән таныкланган кайтарту шартнамәсенә спецификацияләргә туры килә торган нәселле терлек таныклыклары күчермәләре | 5 |
| 5.2. | Зоотехника исәбен алу формаларын алып бару (Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2011 елның 1 февралендәге 25 номерлы боерыгы): | Хисап елының соңгы аена хуҗалык мөһере белән таныкланган актларның берәр нөсхәдә күчермәләре | |
| 5.2.1. | Хайваннар сөтләре пробаларын сайлап алу акты | | . |
| 5.2.2. | Хайваннар буазлыгын билгеләү акты | | . |
| 5.2.3. | Хайваннар экстерьерын бәяләүне үткәрү акты | | . |
| 5.2.4. | Хайваннарны үлчәү акты | | . |
| 5.2.5. | Хайваннар китү акты | | . |
| 5.2.6. | Тән төзелеше тибы буенча сыерны бәяләү карточкасы | Сыерны бәяләү карточкасы күчермәсе | . |
| 5.2.7. | Хайваннарны контроль саву акты | | . |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 6. | Селекция һәм нәселле терлек эше белән идарә итүнең автоматлаштырылган системасын алып бару | | |
| 6.1. | Сөт сыйфатын селекция контролендә тоту лабораториясендә тикшерелгән, шәхси кабинет аша нәселле терлекнең дәүләт регистрында теркәлгән сөтнең сыйфат күрсәткечләрен (май һәм аксым күләмен) системага кертү (хисап елына һәр чыгарып алынган мәгълүмат – 2 балл) | Төбәк мәгълүмат-селекция үзәге мәгълүматлары | 24 |
| 6.2. | Системаны «болыт» версиясендә алып бару | Төбәк мәгълүмат-селекция үзәге мәгълүматлары | 10 |
| 6.3. | Профильле лабораториядән алынган сыерларның барлык геннар җыелмасы паспортларын системага кертү, ана терлекнең булган баш санынnan процентларда (һәр 1% – 0,2 балл) | Селекция һәм нәсел эше белән идарә итүнең автоматлаштырылган системасы картотекасы структурасында хисап, Төбәк мәгълүмат-селекция үзәге мәгълүматлары формалаштырыла | 20 |
| 6.4. | Нәселле хайваннарның чыгышын исәпкә алуны алып бару: нәселле хайваннар шәҗәрәсендә өлкәннәре булу (100%) | Селекция һәм нәселле терлек эше белән идарә итүнең автоматлаштырылган системасы картотекасы структурасында хисап төзелә | 10 |
| 6.5. | Нәтиҗәләрне системага кертеп, комплекслы бәяләүне (бонитировканы) үткәрү (100%) Хаталары булган сыерлар, хаталары булган яшь терлек ачыкланган очракта, баллар куелмый | Төбәк мәгълүмат-селекция үзәге мәгълүматлары буенча селекция һәм нәсел эше белән идарә итүнең автоматлаштырылган системасында хайваннарның комплекслы классын исәпләгәндә хисап формалаштырыла | 10 |
| 7. | Селекция-нәсел эшенең торышы | | |
| 7.1. | Секцияле орлык белән орлыкландыру | Спецификацияне теркәп, шартнамә күчермәсе | 8 |
| 7.2. | Хуҗалыкта эмбрионны трансплантацияләү ысулын куллану | Башкарылган эшләр акты күчермәсе | 4 |
| 7.3. | Хисап елына нәселле хайваннар күргәзмәләрендә катнашу (һәр катнашучы өчен 4 балл бирелә) | Төбәк мәгълүмат-селекция үзәге мәгълүматлары | 4 |
| 7.4. | Нәселле терлекләр күргәзмә- | | 4 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | сендә призлы урыннар алу (һәр призлы урын өчен 4 балл бирелә) | | |
| 7.5. | Терлекләрнең нәсел сыйфатларын комплексы бәяләү, сертификацияләнгән бәяләүчене җәлеп итеп, экстерьерны бәяләүне үткәрү | Шартнамә һәм башкарылган эшләр акты, сертификат бирелә | 20 |
| 8. | Лаборатория тикшеренүләрен үткәрү | | |
| 8.1. | Көтүгә кертелә торган барлык (100%) тана сыерларны паспортлаштыруны үткәрү (ДНК-профиль яисә кан төркеме) | Лаборатория тикшеренүләре нәтиҗәләре күчермәләре | 20 |
| 8.2. | Сөтнең селекция сыйфаты лабораториясендә тикшерелгән, нәселле терлекнең дәүләт регистрында теркәлгән сөтнең сыйфат күрсәткечләрен (май һәм аксым күләмен) тикшерү (1 елга): | Нәселле терлекнең дәүләт регистрында теркәлгән сөтнең селекция сыйфаты һәм аны контрольдә тоту лабораториясе нәтиҗәләре белән раслана | |
| | 950 – 1 000% савым сыеры | | 20 |
| | 600 – 949% савым сыеры | | 15 |
| | 450 – 599% савым сыеры | | 10 |
| 9. | Мөгезле эре терлек үрчетү өчен җайланма булу | | |
| 9.1. | Буазлыкны диагностикалау өчен УЗИ аппаратын куллану | Башкарылган эшләр акты | 7 |
| 9.2. | Җенси ауга чыгуны билгеләү датчигын куллану | Хуҗалыкны тикшергәндә визуаль фиксацияләү | 7 |
| 9.3. | Орлыкны транспортлау өчен термопеналлар булу | | . |
| 9.4. | Җенси ауга чыгуны билгеләү өчен чаралар куллану | | 4 |
| 9.5. | Орлыкны эретү җайланмасы булу | | . |
| 9.6. | Морозов өстәле булу | | . |
| 10. | Ветеринария чаралары | | |
| 10.1. | 0 градустан түбән температурада туңмый торган дезинфекция эремәләре белән дезинфекция барьерлары булу | Хуҗалыкны тикшергәндә визуаль фиксацияләү | 5 |
| 10.2. | Ферма территориясендә ветеринария-санитария таләпләренә җавап бирә һәм территориягә | | 5»; |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | хайваннар (кош-кошлардан һәм вак кимерүчеләрдән тыш) керүне булдырмый торган коймалар булу | | |

әлеге карар белән расланган Агросәнәгать комплексында инвестиция кредитлары (заемнары) буенча процентлар түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башлану көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 19 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә заемга алучыларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 7 пунктындагы икенче абзацы нигезендә бирелә торган заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 8 һәм 9 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

заемга алучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләренең бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган урнаштыру датасын.»;

8 пунктта:

икенче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктның алтынчы абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

6 пунктның өченче абзацында «килешү» сүзен «шартнамә» сүзенә алмаштырырга;

20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Бирелгән субсидия Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә түбәндәге рәвештә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча шартлар бозылган, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап бирелмәгән очракларда;

субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгән очракта, Министрлык субсидия алучыга карата түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла торган штраф санкцияләрен ($V_{кайтару}$) куллана, почта аша тапшыру турындагы хәбәрнамәне теркәп, срогын һәм түләү реквизитларын күрсәтеп, килешүдә билгеләнгән, субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисап алынган датадан эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә штраф санкцияләрен куллану турында хәбәрнамә җибәрә:

$$V_{кайтару} = (V_{субсидия} \times k) \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{субсидия}$ – хисап финанс елында нәтиҗәгә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме;

k – түбәндәге формула буенча билгеләнә торган субсидияне кире кайтару коэффициенты:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән мәгънәсе;

S – килешүдә субсидия алучы өчен билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча мәгънәсе.

Штраф санкцияләрен исәпләп чыгарганда бары субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган коэффициентның уңай мәгънәләре кулланыла.»;

22 пунктта «Россия Федерациясе законнары нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга, «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә һәм (яки) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибендә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башлану көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 15 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 7 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 8 пунктындагы икенче абзацы нигезендә бирелә торган заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

әлеге Тәртипнең 9 һәм 10 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүләргә (алга таба – килешү) имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

бердәм порталда һәм рәсми сайтта сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы, ул сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соң булмаска тиеш.»;

9 пунктта:

икенче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «сайлап алуны үткәрү» сүзләрен «заявкалар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга.

17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Бирелгән субсидия Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә түбәндәге рәвештә Татарстан Республикасы бюджеты керемено кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча шартлар бозылган, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап бирелмәгән очракларда;

субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәгән очракта, Министрлык субсидия алучыга карата түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла торган штраф санкцияләрен ($V_{кайтару}$) куллана, почта аша тапшыру турындагы хәбәрнамәне теркәп, срогын һәм түләү реквизитларын күрсәтеп, килешүдә билгеләнгән, субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисап алынган датадан эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә штраф санкцияләрен куллану турында хәбәрнамә җибәрә:

$$V_{кайтару} = (V_{субсидия} \times k) \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{субсидия}$ – хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме;

k – субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган коэффициент:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән мәгънәсе;

S – килешүдә субсидия алучы өчен билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча мәгънәсе.

Штраф санкцияләрен исәпләп чыгарганда бары субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган коэффициентның уңай мәгънәләре кулланыла.»;

19 пунктта «Россия Федерациясе законнары нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга, «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

әлеге карарга Виноградчылыкны һәм шәраб әзерләүне үстерүне

стимуллаштыруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибен, «Агросәнәгать комплексы продукциясен экспортлау» федераль проекты кысаларында чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибен, Ана сарык һәм кәҗәләрнең, шул исәптән бер яшьтән өлкәнрәк ана сарык һәм кәҗә бәрәннәренең баш санын саклап калу һәм үстерү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибен, Яшелчәләр җитештерүне үстерүне стимуллаштыруга юнәлдерелгән чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибен (карарга теркәләләр) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин